# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырты авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

09 ноябрь, 2024 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан (курсантлардан), I төркем инвалидларыннан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә:

урам яктыртуны тәэмин итү (махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү, урам яктыртуны тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (комплектлаучы әйберләрне сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета эшләү һәм түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү ситсемасын карап тоту, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, насос сатып алу һәм урнаштыру);

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (чишмә территориясен төзекләндерү, койма һәм баскычларны ремонтлау һәм буяу, материаллар сатып алу һәм ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм түләү, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төрле әшләр);

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (смета төзү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, янгынга каршы җиһазларны сатып алу, урнаштыру, башка төрле эшләр);

һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне карап тору, смета төзү һәм түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, башка төрле эшләр);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нырты авылында урамындагы юлларга вак таш җәю, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; кыш көне Нырты авылы юлларын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, смета төзү һәм түләү; башка төрле эшләр);

торак пункт территориясен төзекләндерү (агачларны һәм куакларны кисү, чүп түгү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү, материаллар сатып алу һәм ташу; җәйге чорда территорияне чабу, куакларны һәм агачларны кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү; спорт мәйданчыгын карап тору, смета төзү һәм түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү; башка төрле эшләр;

Сабантуй бәйрәмен үткәрү территориясен төзекләндерү һәм төзекләндерү килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм түләү, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр;

ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны карап тоту, инвентарь һәм кирәкле матераллар сатып алу, ташу, смета төзү һәм түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, башка төрле эшләр);

каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (смета документациясен эшләү һәм түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, технадзорны гамәлгә ашыру, каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын урнаштыру һәм аларга якын территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр;

Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т.А.Кутдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710